МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.01.2023 Казан ш № 41

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты гамәленең гражданнарның аерым категорияләренә кагылуы турында» 2022 елның 30 июнендәге 651 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 16 мартындагы 376 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 ноябрендәге 880

номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнарны укудан буш вакытында, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны, урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм алган белем турында һәм квалификация турында документ бирелгән датадан башлап бер ел дәвамында эш эзли торган 18 яшьтән 25 яшькәчә булган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты гамәленең гражданнарның аерым категорияләренә кагылуы турында» 2022 елның 30 июнендәге 651 номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2022 елда» сүзләрен «2022 һәм 2023 елларда» сүзләренә алыштырырга;

1 пунктта «2022 елның 31 декабренә кадәр» сүзләрен «2023 елның 31 декабренә кадәр» сүзләренә, «Административ регламентның 3.8.1 пунктындагы 2 пунктчасының дүртенче һәм тугызынчы абзацларыннан, 3.9.1 пунктындагы 5-7 пунктчаларыннан, 3.9.5-3.9.8 пунктларыннан тыш» сүзләрен «3.1 пунктындагы 8 пунктчасыннан һәм 3.9 пунктыннан тыш» сүзләренә алмаштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова